ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

12 03 20 20 г. № 169

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 гыйнварындагы 12 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торглар үткәрү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы «Реклама турында» Федераль закон нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 гыйнварындагы 12 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торглар үткәрү тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 2-нче кушымтаның 8.2 пунктындагы 5 абзацында

беренче җөмләдә «гариза бирүченең мөһере белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

икенче җөмләдә «гариза бирүченең мөһере белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның тышкы реклама белән эшләү бүлеге башлыгы С.П. Прохоровка йөкләргә.

Житәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874